| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Крындинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кырынды авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.10.2019 Кырынды авылы № 3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге Еленовск авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге башлыгы к а р а р б и р д е:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2019 елның 19 октябренә 12 сәг. 00 мин. Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Еленовск авылы, Красная ур., 13 йорт адресы буенча билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга: «I төркем инвалидларыннан, өлкән яшьтәге гражданнар (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, иректән мәхрүм итү урыннарында булган затлардан тыш, Кырынды авыл җирлеге Еленовск авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2020 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә, Сез ризамы:

1. Еленовский авылындагы Красная урамы буенча юлны ремонтлау һәм вак таш җәю.

«ӘЙЕ» «ЮК».

2. Кырынды авыл җирлеге Башкарма комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

И. И. Закиров